/Безнең уңышлар/




## Тукай безнең күңелләрдә

Апрель ае бөек шагыйребез – Габдулла Тукайны биргән ай. Ел саен шул хөрмәткә укучылар катнашында төрле чаралар уздырыла. Быел да мәктәптә шагыйрьгә багышланган кичә үткәрелде. Балалар яттан Тукай шигырьләрен сөйләделәр, инсценировка ясадылар, тормыш юлына багышланган презентация карадылар. Укучылар арасында шигырь ятлау конкурсларын ешрак үткәрергә дигән карарга да килдек.

20 нче апрельдә Аксубайның 1 нче мәктәбендә "Без Тукай оныклары "дигән районкүләм чара уздырылды. Муниципаль конкурска һәр мәктәптән бер чыгыш таләп ителгән иде. Безнең Х сыйныф укучысы **Морадимов Илсур** Тукайның "Китмибез" шигырен сөйләп, җиңүче исеменә лаек булды. Илсурның чыгышына тиңнәр булмады . Укучыбыз сәхнәне бик ярата, бик күп чараларда катнаша һәм уңышларга ирешә. Җиңүең белән котлыйбыз, Илсур!

***Фәнүзә Гафиятуллина , татар теле әм әдәбияты укытучысы***

/ Чал тарихта эзле без /

## Югары кыр

“Югары кыр” – туган ягыбызның гүзәл бер почмагы. Борынгы бабаларыбыз тәүге нигезләре шушы урында булганлыктанмы, бу кырда йөрү күңелне хозурландыра, җанга сихәт бирә.



Югары кыр күренеше

Элек заманнарда авылның җирләре югары һәм түбән кырларга бүленеп йөртелгән. Чирмешән елгасын сул ягындагы далалар – “түбән кыр“, ә уң яктагы таулы җирләр – “югары кыр“ дип аталган. Авылның 1860 нчы елларга караган хуҗалык тасвирламасында бу кырлар түбәндәгечә билгеләп үтелгән: *“а) Земли, лежащия на левой стороне реки Малаго Черемшана, отстоят от усадьбы на 5 верст; положение ровное, открытое, степное, в общем характер слабо покатое к руслу речки; почва лучший темно-буро-серый, глинисто-песчаный чернозем, с значительною примесью перегноя, глубиною до 17 вершков, подпочва красно-бурая глина с песком. Эти земли составляют 1-й разряд.*

*б) Земли, лежащия на правой стороне речки Малого Черемшана, отстоят от усадьбы на 3,5 версты с положением гористым, сильно покатым к руслу реки; почва буровато-серый, песчано-глинистый (суглинистый) чернозем, с едва заметною примесью перегноя, глубиною до 10 вершков, подпочва красная глина. Эти земли отнесены ко 2-му разряду.”* Югары кырның кызыл балчыгы кирпеч сугар өчен яраклы санала һәм моны элеккеге бабайлар да белгәннәр. Саржинат куаклыгы турысында тауга түгәрәк рәвешендә уелып кергән чокыр кирпеч сугып яндырылган урын буларак билгеле.

1750 нче елларда хәзерге урынына күчкәнчегә кадәр безнең авыл Югары кырның аскы өлешендә урнашкан булган. Кырның калган өлешен куе урман билән торган. 1772 нче елга караган Биләр авылы җирләрен межалау кенәгәсендә бу урман *“дровяной лес деревень Черемшанов, Студеные Ключи тож”* дип күрсәтелгән. Шул урманның истәлеге булып Югары кырның көнбатыш ягында берничә урында әле дә дистәгә якын имән агачлары шаулап үсеп утыралар. Бу урман безнең авылның урман биләмәсе булганлыктан, аның агачлары хуҗалык кирәге өчен XX гасыр башларына инде киселеп беткән. 1920 нче елларга чаклы Югары кырның Чәчәби тавына кадәрге өлеше безнең авыл биләмәләренә кергән.

***Рафик Насыйров, тарих укытучысы, тарих фәннәре кандидаты***

/Котлыйбыз!/



Ямьле яз ае-апрельдә үзләренең туган көннәрен билгеләп үтүче укучыларыбыз **Хафизов Ирекне, Залиева Василәне** чын күңелдән котлап сау-сәламәт булып үсүләрен һәм укуларында тырышлык телибез. Укучыларыбызга бары тик уңышлар гына елмайсын.

Мәктәп хезмәткәрләреннән **Кадыйрова Гөлнур апа** белән **Йосыпова Айгөл апаларны**, **Туктамышев Рифкать** һәм **Сафиуллин Илдар абыйларны** гомер бәйрәмнәре белән котлап сәламәтлек, озын гомер, гаиләләрегенә иминлек телибез.

**Газетаны гамәлгә куючы** – Түбән Майна урта мәктәбе
**Мөхәррир** – Фәнүзә Гафиятуллина
**Редколлегия әгъзалары:** Әминә Туктамышева, Виктория Нукина, Зөлфирә Сафиуллина

# Мәктәп хәбәрчесе

№4
(№45)
апрель
2023 ел

Түбән Майна урта мәктәбе газите

Тел. 8 (84344) 4-38-46 sch1644maina@mail.ru

/ Безнең бәйрәмнәр /

## Авылда экологик гает

Күптәннән килгән гадәт буенча, безнең авылда гает бәйрәмнәре балалар өчен төрле чаралар оештыру белән билгеләп үтелә. Быелгы Рамазан гаете язгы өмәләр чорына туры килгәнлектән, бәйрәмне күңелле генә түгел, файдалы да итеп уздырырга карар кылынды. Ислам дине чисталыкка нигезләнгәнлеген беләбез. Кешенең тәне, киеме, өе генә түгел, яшәү тирәлеге дә чиста булырга тиеш. Шунлыктан халкыбыз әлек-электән чисталыгы, пөхтәлеге, авылларының матурлыгы белән дан тоткан. Әлеге күркәм сыйфатлар яшь буынга да тапшырылыра тиеш. Авыл тирәсе җыештырылган, чиста булса, шунда торучылар өчен уңай яшәү шартлары барлыкка килә, ә читтән килүчеләр өчен яхшы үрнәк күрсәтелә.



Быелгы өмә мәктәп тирәсен җыештырудан башланып китте. Гает бәйрәменең икенче көнендә укучылар, укытучылар көче белән дә Чирмешән елгасы тирәсен, әрәмәлекне җыештырдык. Елга буендагы агып килгән чүпләрне, корыган агачларны күргәч эшнең күплегеннән куркып калсак та, кумәк эш тау күчерә дигәндәй, бергәләшеп җиңел чыктык. Эшләр төгәлләнгәч Чирмешән буендагы карт тирәк агачы янына җыелыштык. Биредә өмәдә катнашучыларны гает чәе белән корбан итеннән әзерләнгән шашлык көтә иде. Бәйрәм сыйлары белән тукланганнан соң Рафик абый балаларга гает күчтәнәчләре тутырылган пакетлар өләште. Узган Рамазан аенда мәчеткә тәравих намазына йөргән укучыларга аерым зур бүләкләр тапшырылды.

Менә шулай итеп, экологик гает бәйрәме күңелле генә узып китте. Күмәкләшеп эшләгәндә авырлыклар да, арулар да онытыла. Авылыбыз һәрвакыт чисталык үрнәге булып торсын иде, чөнки ул безнең уртак йортыбыз. Чирмешән – туган ягыбызның сокланып туймаслык гүзәллеге. Урамнар, болыннар һәм елга буйларыбыз һәрвакыт чиста булып торсын. Безнең йортны үзебездән кала беркем дә килеп тәртипкә салып тормас. Туган җиребезнең кадерен һәм үзебезнең дәрәҗәбезне белеп яшик!

***Фәнүзә Гафиятуллина, татар теле һәм әдәбияты укытучысы***

/Мәктәп тормышы /



## Сыйныф сәгатьләрендә

1906 нчы елның 1 нче апрелендә кошларны саклау буенча Халыкара конвенциягә кул куела. Россия моңа 1920 нче елда кушыла. Шулай итеп кошлар көнен үткәрү традициягә кергән. Без дә бу чарада кушылдык. Башлангыч сыйныф укучылары арасында "Кошлар тавышы бер дә тынмасын" дип аталган девиз астында КВН уздырылды. Укучылар канатлы дусларыбыз турында кызыклы мәгълүматлар белән таныште. Кошлар турындагы табышмакларга җаваплар таптылар, әйтемнәрне искә төшерделәр. Чара ахырында рәсем конкурсы үткәрелде.

Шулай ук узган айда балаларның сәламәтлек турында күзаллауларын киңәйтү максатыннан "Дөрес туклану – сәламәтлек нигезе" дип аталган сыйныф сәгатьләре үткәрелде. Бу чарадан укучылар дөрес туклану белән сәламәтлекнең ныклы бәйләнештә булуына төшенделәр.

Тәрбия сәгатьләребезнең берсе истәлекле датага багышланган иде. 1961 нче елның 12 нче апрелендә совет космонавты Юрий Гагарин "Восток-1" космик корабында "Байконур" космодромыннан старт алган һәм дөньяда беренче кеше булып Җир шарын урап очкан. Космоста очу вакыты 1 сәгать 48 минут дәвам иткән. Космонавтика көненә багышланган төрле чаралардан тагын башлангыч сыйныф укучылары рәсемнәр ясадылар.

***Ләйлә Нургалиева, VII сыйныф укучысы***

## / Безнең сәяхәтләр /



### Онытылмас сәяхәт

26 нчы апрель көнне безнең укучылар, укытучылар һәм әти-әниләрдән тупланган туристик төркем, мәктәп яныннан зур матур автобуска утырып, Мәскәүгә сәфәргә кузгалды. Моңа кадәр шундый ерак җирләргә сәяхәтләр 2018 һәм 2019 нчы елларда оештырылган иде. Аннан соңгы елларда, COVID эпидемиясе сәбәпле, мондый сәфәрләр туктатылып торды. Директор Рафик абый әйтүенчә, безнең һәр укучы мәктәпне тәмамлаганчы үзебездәге Болгар, Казан, Кырлай кебек туризм үзәкләрен генә түгел, ә Мәскәү һәм Питер шәһәрләрен дә күреп кайтырга тиеш. Быелгы сәфәр дә шул максаттан чыгып оештырылды.

Сәфәребез башында Казанда тукталып "Мин татарча сөйләшәм" чарасында катнашу, Иске Татар бистәсе белән танышырга ниятләгән идек. Без Казанга барып җиткәндә яңгыр сибәли башлады. Шуңа да карамастан, билгеләнгән маршрут буенча Иске бистә буйлап җәяүләп йөреп, кичке ашны “Сөембикә” кафесында ашап, тимер юл вокзалына барып җиттек. Поездда сәяхәт итү дә күпләребез өчен яңалык иде.

Мәскәүгә без икенче көнне иртән барып җиттек. Алдан сөйләшкән буенча, Мәскәүнең Казан вокзалында безне гид белән сәяхәтне оештыручы Лилия апа көтеп тора иде. Иң башта без автобус белән Мәскәүне карап йөрдек. Андагы хис-кичерешләрне сөйләп тә, язып та бетереп булмый. "Кызыл Мәйдан", "Поклонная гора", "Москва Сити", "Воробьевы горы"... Башкаланың әлеге урыннарны бай тарихлы һәм искиткеч матур. Гид Юля апа бик кызыклы итеп сөйләп барды. Мәскәү белән танышу төгәлләнгәч без "Бородино сугышы” панорамасына килдек. Анда кергәч үзебезне нәкъ 1812 нче елга күченгән кебек хис иттек. Үлгән атлар, сугышчылар, җимерелгән өйләр, ташлап калдырылган туплар арасында рус-француз сугышы чынбарлыкта барган шикелле булды.

Икенче тукталышыбыз “Поклонная гора” тарихи комплексындагы Җиңү музее булды. Бирегә без Бөек Ватан сугышы мохитына кереп чумдык. Сугышның иң хәлиткеч вакыйгалары сурәтләнгән диорамалар тарих китабындагы кебек кенә түгел шул. Сәяхәт программасы бик тыгыз булганлыктан “Поклонная гора”дагы барлык күргәзмәләрне дә карап булмады. Бирегә тагын килергә кирәк икән дигән фикер калды бездә. Андагы мәчеткә кереп чыккач, ВДНХ күргәзмәсенә юл алдык.



ВДНХда без ике урынга кердек. Океанариумда безне гомердә дә күрмәгән балыклар, акулалар, ташбакалар белән очрашу көтә иде. “Космос” павильоны укучылар күңелендә бик күп истәлекләр калдырды. Андагы экспонатларның күпчелеге космосны үзләштерүдә катнашкан чын аппаратлардан гыйбарәт. Биредәге экскурсия барышында космос темасын якын итүчеләр өчен бик күп яңалыклар ачыкланды.Сәяхәтнең беренче көне теплоходта Мәскәү елгасы буйлап йөзеп, төнге башкаланы манзара кылу белән төгәлләнде. Аннан соң 3 йолдызлы кунакханәгә кайтып кундык, үзебезне тәртипкә китердек, ял иттек.

Икенче көнебез илнең иң биек корылмаларыннан булган Останкино телевидение манарасына менү белән башланып китте. Бик катлаулы тикшерү аркылы узып, без 337 метр биеклектән Мәскәү белән югарыдан таныштык. Останкинодан соң сәяхәтебез Кремль тирәсендәге истәлекле урыннарда дәвам итте. Анда безне Юля апа Мәскәү һәм Кремль тарихы белән махсус әзерләгән квест аркылы таныштырды. Укучылар ике командага бүленеп, Мәскәү ачкычына ия булу өчен төрле биремнәр үтәделәр, сорауларга җавап бирделәр. Квест төгәллләнгәч Кремль эчендәге “Оружейная палата” музеена кердек. Биредә патшаларның киемнәре, короллары, зиннәтле әйберләре, тормыш-көнкүреше белән таныштык. Көтеп алган сәяхәтебез Мәскәүдәге иң зур "Җәмигъ" мәчетендә төгәлләнде.

Шундый тыгыз һәм нәтиҗәле программаны, алдан ук экскурсияләргә һәм автобуска заказ бирел хәрәкәт маршрутларын билгеләмичә башкарып чыгу мөмкин булмас иде. Боларның барысын да Мәскәүдә яшәүче хөрмәтле якташыбыз Вәлиева Лилия Кирам кызы югары дәрәҗәдә оештырды. Экскурсияләр барышында үзе дә һәрвакыт безнең белән булып, ашарга да вакытында китерүне оештырып, вокзалга кадәр озата килде. Юлыбызга да һәрберебезгә туклану өчен ланч-бокслар әләште. Кучтәнәчкә Мәскәүнең тәмле туңдырмасын да поездга китерде. Лилия апага шундый тулы, мавыктыргыч итеп оештырган сәяхәт өчен олы рәхмәтләр әйтеп, апрельнең 28 ендә кичке 7 дә туган якка кузгалдык.

Мәскәү сәфәре бик матур узса да, гаиләләребезне, туган авылларыбызны сагынышып кайттык. Укучылар мондый сәфәрләрдә тормыш өчен кирәкле булган күптөрле күнекмәләр – чит шәһәрдә, вокзалда, кунакханәдә, тимер юл транспортында үз-үзеңне тоту тәртипләрен дә өйрәтәләр. Сәяхәт сәяхәт инде, күңелләрдә әле дә җылы хис тора. Туган илебезне өйрәнүләр киләчәктә дә дәвам итсә иде. Илләребез тыныч булып, укучыларыбызга һәрдаим мавыктыргыч сәяхәтләр оештыра алсак иде дигән теләктә калабыз.

***Гөлшат Закирова, башлангыч сыйныфлар укытучысы.***

## /Мәктәп тормышы /

### 3D мастер классы



22 нче апрель көнне безнең белән очрашугa авылга әтиләренә кунакка кайткан Хәйруллин Мансур абый килде. Ул бүгенге көндә 3D-модельләштерү белән шөгыльләнүче буларак, безгә мавыктыргыч мастер класс үткәрде. Үз эшенең остасы булган Мансур абый үзенең 3D принтерында без теләгән брелокны чыгартып күрсәтте. Без бу очрашуда хәзерге заман технологияләренең күз алдына китерә алмаслык могҗизалар тудыруына сәләтле икәнен күрдек. Бүгенге көндә мондый принтерлар вак-төяк әйберләр генә түгел, шулар ярдәмендә өйләр дә төзиләр икән. Төрле фантастик фильмнар төшергәндә дә 3D-технологияләр киң кулланыла , ди. Ләкин техника үзе генә берни дә булдыра алмый, әгәр аны эшләтә белә торган кешеләр булмаса. Моның өчен мәктәптән ук тырышып укырга кирәк. Чөнки “башлы” машиналарны башлы кеше генә дөрес итеп эшләтә ала.

***Рәсим Йосыпов, VII сыйныф укучысы***

### Куркынычсыз тәгәрмәч



20 нче апрель көнне Аксубайның 2 нче мәктәбеендә "Куркынычсыз тәгәрмәч" республика конкурсының район туры үтте. Районның 14 мәктәбеннән килгән ЮИД отрядлары көч сынашты. Конкурс бернечә этаптан торды. Алдан укучылар велосипедларда төрле сынаулы маршрут буйлап йөрде. Аннан юл йөрү кагыйдәләрен белүгә, беренче медицина ярдәме күрсәтү, велосипед төзелешен буенча сынаулар үттек. Нәтиҗәдә, мин, **Закирова Ләйсән** "ПДД белгече" номинациясендә II урын, отряд җитәкчесе **Руфия апа Гафиятуллина** "Иң яхшы ЮИД отряды җитәкчесе" номинациясендә III урын алдык.

Безнең ЮИД отряды бернечә ел инде уңышлы эшләп килә. Руфия апа белән укучылар юл йөрү кагыйдәләрен тирәнтен өйрәнәләр. Безгә киләчәктә машина йөртү таныклыгы алырга да җиңел булыр инде ышанабыз.

***Ләйсән Закирова, V сыйныф укучысы***

## /Укучылар иҗаты/



### Туган як кадере

Менә авылыма янә матур яз килде. Ашыгып-ашыгып урамнарны яшеллеккә күмде. Кошлар сайравы яр буйларында талларга күчте. Кар эреп беткәнне күрми дә калдым. Җир үзенә барлык дымны йотып калырга ашыккандай, һәр тамчысын тәмләп кабып куйды.

Мәктәптән кайтканда да, бакчада эшләп йөргәндә дә дөньямны онытып күзәтеп йөрим. Авылыбызның матурлыгы һәркемне сокландырырлык. Күмәкләшеп җыештырып та куйгач, тагын да сафланып китте. Урамымда кич белән ак яулыклы күрше әбиләрем утырса, тагын да күркәмлек өстәлә. Алар барысы да узган-барганга сәлам биреп, исәнлек теләп дога кылып калалар. Кеше кадере, күршеләр кадере шулай барлыкка киләдер дип уйлыйм. Шәһәр урамы мондый иркенлекне, мондый бердәмлекне бирми шул...

Кич белән көтү кергәндә тагын бер-береңнең хәлен белү башлана. Әниләр, әбиләр сөтлебикәләрен каршыларга җыелган була. Эре-эре атлап кайткан сыерлар барлык витаминнарны кушып җыйган сөтләрен “тапшырырга” ашыга.

Сыерлар савылгач авыл тын кала. Шуны гына көткәндәй талда сандугач сайрап җибәрә дә, яшелчәләреңә су сипкәнеңне онытып, туктап моңга чумасың. Аларның сайравына судагы балыклар да кушылып кызурак йөзә, кондызлар агачларын катырак кимерергә тотына кебек. Якынрак килеп тыңласаң, барысының да тавышын тыңлап була. Я, әйтегез, мондый шифаханәнең кадерен белми буламы? Аккошлар да әнә безнең авылны сайлады, күлебезгә килеп “тормыш корганнар”.

Һәркемнең үз туган җире матур да, кадерле дә инде ул. Тик шулай да минеке матуррак кебек.

***Зөлфирә Сафиуллина, XI сыйныф укучысы***